**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«29» июль, 2019 ел Круглое Поле п. № 12

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2017 елның 11 декабрендәге 12 санлы карары белән расланган «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р санлы боерыгын тормышка ашыру максатыннан

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2017 елның 11 декабрендәге 12 санлы карары белән расланган «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 1435 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- район бюджеты һәм авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына 1435 мең сум |

1.2. 3 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

**«3. Программаны финанслау**

Программаны финанслауның гомуми күләме 1 435 мең сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финансларны бүлүче – авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе, район Башкарма комитеты Җитәкчесе.

Финанслауның күрсәтелгән күләме тиешле финанс елына бюджет формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш. Моннан тыш, мөмкин булганда, район бюджеты акчалары, максатчан һәм ирекле иганәләр җәлеп ителәчәк.»;

1.3. 2018-2020 елларга Круглое Поле авыл җирлеге буенча юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү программасын яңа редакциядә бәян итәргә:

2018-2020 елларга Круглое Поле авыл җирлеге буенча юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү программасы

| № | Объект исеме | Ераклык | Финанслау чыганаклары | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Җирле бюджет, сумнарда | | | |
| | | | 2018 | 2019 | 2020 | |
| 1. | Авыл эчендәге юлларны төзү, ремонтлау һәм реконструкцияләү: | | - | 390,00 | - | |
| 1.1 | Зеленая ур. | 0,2 | 150,00 | - | - | |
| 1.2 | Раздольная ур. | 0,5 | 375,00 | - | - | |
| 1.3 | Яшьләр ур. | 0,25 | 300,00 | - | | |
| 1.4 | Солнечная ур. | 0,05 | 60,00 | - | | |
| 1.5 | Мәктәп тыкрыгы | 0,1 | 60,00 | - | | |
| 1,6 | Гагарин ур. | - | - | 390,00 | - | |
| 2. | Җирлек торак пунктларында тукталыш павильоннарын урнаштыру | - | - | - | - | |
| 3. | Җирлектә гомуми белем бирү учреждениеләре каршында балалар автомобиль мәйданчыклары | - | - | - | - | |
| 4. | «Ясалма тигезсезлек» урнаштыру | | 21,805 | - | 50,00 | |
| 5. | Юлның машиналар йөрү өлешенә разметка | - | - | 10,00 | - | |
| 6. | Авыл җирлегендә юл билгеләре урнаштыру | - | 18,195 | - | - | |
| 7. | Юл буе сервисы объектлары булган участокларда юлларны яктырту | - | - | - | - | |
| 8. | Авыл эчендәге юлларда яктырткычлар урнаштыру | - | - | - | - | |
| 9. | Металлдан барьер коймалар урнаштыру | - | - | - | - | |
| | БАРЛЫГЫ | | 985,00 | 400,00 | 50,00 | |

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Э.Р. Низамиева